# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «үсешендә хилафлык булган» сүзләрен «сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяның 2 өлешендә «үсешендә хилафлык булган» сүзләрен «сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

3) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне оештыру, белем бирү учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү, инновацион белем бирү программаларын гамәлгә кертүче гомуми белем бирү учреждениеләренә акчалар бирү буенча вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелүче субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативны исәпләп чыгару**

# МЕТОДИКАСЫ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнде.

Методика сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне оештыру, белем бирү учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү, инновацион белем бирү программаларын гамәлгә кертүче гомуми белем бирү учреждениеләренә акчалар бирү буенча Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) финанс ягыннан тәэмин итү өчен кирәкле чаралар күләмен билгеләүнең ысулый нигезләрен урнаштыруга юнәлдерелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА БИРЕЛҮЧЕ СУБВЕНЦИЯНЕҢ ГОМУМИ КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘП ЧЫГАРУ

1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетка билгеләнгән субвенция күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = Sk_i + Sm_i + Sy_i + S_{in},$$

монда:

$S_i$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга і-муниципаль берәмлеге өчен субвенция күләме;

$Sk_i$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне оештыру буенча вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме;

$Sm_i$ – мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итүне оештыру вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме;

$Sy_i$ – Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләре өлкәсендә идарә чыгымнарын гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме;

$S_{in}$ – инновацион белем бирү программаларын гамәлгә кертүче гомуми белем бирү учреждениеләренә акчалар бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме.

2. Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне оештыру буенча вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме ($Sk_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Sk_i = (\sum_{i=1}^{n} \sum_{j=1}^{m} \sum_{k=1}^{l} (H_{ijk} \times (R_{ijk}^{t} + N_{ijk}^{t})) + \sum_{j=1}^{m} \sum_{k=1}^{l} (H_{jk}^{gpd} \times (R_{ijk_{gpd}}^{t} + $$
$$+ 12 \times BNSI_{k_{gpd}}^{t} \times K_{NSI_y}{}^{gpd}) + 12 \times \sum_{y=1}^{z} BNSI_{k}^{t} \times K_{NSI_y} \times So_y) \times kv ,$$

монда:

$H_{ijk}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә укучылар (тәрбияләнүчеләр) категорияләре, укыту баскычлары һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча укучылар (тәрбияләнүчеләр) саны;

$H_{jk}^{gpd}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләренең, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләренең озайтылган көн төркемнәрендә укучылар, тәрбияләнүчеләр категорияләре һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча укучылар (тәрбияләнүчеләр) саны;

$R_{ijk}^{t}$ – мәгариф учреждениеләрендә һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә укучылар (тәрбияләнүчеләр) категорияләре, укыту баскычлары, территориаль дислокация һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча финанс чыгымнары нормативы;

$N_{ijk}^{t}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга укучылар (тәрбияләнүчеләр) категорияләре, укыту баскычлары, территориаль дислокация һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча финанс чыгымнары нормативы;

$R_{jk_{gpd}}^{t}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләренең, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләренең озайтылган көн төркемнәрен укучылар (тәрбияләнүчеләр) категорияләре, укыту баскычлары, территориаль дислокация һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча финанслау нормативы;

12 – елдагы айлар саны;

$BNSI_{k_{gpd}}^{t}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә озайтылган көн төркемнәре мөлкәтен карап тотуның территориаль дислокация һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча база нормативы;

$K_{NSI_y}^{gpd}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) *у*-мәгариф учреждениесенең, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы *у*-мәгариф учреждениесенең, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен *у*-мәгариф учреждениесенең озайтылган көн төркеме мөлкәтен карап тотуның база нормативына төзәтмә коэффициент;

$BNSI_k^t$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениесе, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениесе, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениесе мөлкәтен карап тотуның территориаль дислокация һәм мәгариф учреждениеләре төрләре буенча база нормативы;

$K_{NSIy}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) $y$-мәгариф учреждениесе, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы $y$-мәгариф учреждениесе, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен $y$-мәгариф учреждениесе мөлкәтен карап тотуның база нормативына төзәтмә коэффициент;

$So_y$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) $y$-мәгариф учреждениесе, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы $y$-мәгариф учреждениесе, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен $y$-мәгариф учреждениесе биналарының һәм корылмаларының җылытыла торган мәйданы;

$kv$ – мәгариф учреждениеләренең формалашкан челтәрен финанслаудан белем бирү хезмәте күрсәтүне финанслауга «йомшак күчүне» истә тотучы тигезләү коэффициенты;

$i$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә укыту баскычлары;

$j$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр категорияләре;

$k$ – мәгариф учреждениеләре төрләре;

$n$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә укыту баскычлары саны;

$m$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр категорияләре саны;

$l$ – мәгариф учреждениеләре төрләре саны;

$z$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләре, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләре, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләре саны;

$t$ – мәгариф учреждениесенең территориаль дислокациясе (шәһәр, авыл җирлеге).

2.1. Мәгариф учреждениеләрендә һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләренең, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләренең озайтылган көн төркемнәрен финанслау нормативы ел саен Татарстан Республикасы законы белән раслана.

2.2. Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләрендә, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләрендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс чыгымнары нормативлары, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениеләренең, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениеләренең озайтылган көн төркемнәре мөлкәтен карап тотуның база нормативы, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениесе, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениесе, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениесе мөлкәтен карап тотуның база нормативы, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениесенең, озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы савыктыручы мәгариф учреждениесенең, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен мәгариф учреждениесенең озайтылган көн төркемнәре мөлкәтен карап тотуның база нормативына һәм аның мөлкәтен карап тотуның база нормативына төзәтмә коэффициентлар, мәгариф учреждениеләренең формалашкан челтәрен финанслаудан белем бирү хезмәте күрсәтүне финанслауга «йомшак күчүне» истә тотучы тигезләү коэффициенты ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итүне оештыру буенча вәкаләтләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар күләме (Smi) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Sm_i = Чр_i \times N_i + Y_{усл} + Y_{сос} + Y_{смз},$$

монда:

$Чр_i$ – i-муниципаль берәмлегендә мәгариф өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиаллары белгечләренең планлаштырылган саны;

$N_i$ – i-муниципаль берәмлегендә мәгариф өлкәсен мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиалының бер белгеченә хезмәт хакын түләү чыгымнары нормативы;

$Y_{усл}$ – хезмәт күрсәтүләргә чыгымнар;

$Y_{сос}$ – төп чаралар бәясен арттыруга чыгымнар (капиталь төзелеш чыгымнарыннан тыш);

$Y_{смз}$ – матди запаслар бәясен арттыруга чыгымнар һәм башка чыгымнар.

3.1. I-муниципаль берәмлегендә мәгариф өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиалының бер белгеченә хезмәт хакын түләү чыгымнары нормативы ($N_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$N_i = Зот_i + Нз_i,$$

монда:

$Зот_i$ – i-муниципаль берәмлегендә мәгариф өлкәсен мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиалы белгеченең уртача хезмәт хакы күләме;

$Нз_i$ – исәп-хисап чорына хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр.

3.2. Мәгариф өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиаллары белгечләре хезмәте өчен түләү чыгымнарын исәпләү Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге норматив хокукый актлары нигезендә исәп-хисап чорына кадәрге чорда мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы белгечләрнең хезмәте өчен түләү фондын һәм исәп-хисап чорына хезмәт хакын арттыру индексын тапкырлау юлы белән башкарыла.

3.3. Мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органында хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр чыгымнары исәбенә эш бирүче тарафыннан федераль бюджетка, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бюджетына (производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәрен дә кертеп), Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды һәм территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт хакларына карата күчерелә торган түләүләр керә.

Хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләргә чыгымнарны ($Нз_i$) исәпләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Нз_i = Зот_i \times Снз ,$$

монда:

$Зот_i$ – i-муниципаль берәмлегендә мәгариф өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиалы белгеченең уртача хезмәт хакы күләме;

$Снз$ – хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр ставкасы.

3.4. Мәгариф учреждениеләрен мәгълүмати тәэмин итү буенча башка чыгымнар тоту исәбенә чыгым материаллары сатып алу, командировкалар, элемтә хезмәте күрсәтүләр, производствога карамаган җиһазлар сатып алу чыгымнары кертелә һәм, мәгариф өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү һәм контроль үзәге филиалының бер белгеченә фактта тотылган чыгымнардан чыгып, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше мөмкинлекләреннән чыгып, индекс-дефляторлар кулланып билгеләнә.

4. Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләре өлкәсендә идарә итү чыгымнарын гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар күләме (Syi) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Sy_i = Зот_i + Нз_i + Пр_i ,$$

монда:

$Зот_i$ – исәп-хисап чорына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда i-муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$Нз_i$ – исәп-хисап чорына i-муниципаль берәмлегенең хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр;

$Пр_i$ – исәп-хисап чорына i-муниципаль берәмлегенең башка чыгымнары.

4.1. Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәт хакы Татарстан Республикасының гамәлдәге норматив хокукый актлары нигезендә исәпләнә.

Исәп-хисап чорына хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары исәп-хисап чорына кадәрге чорда хезмәт өчен түләү чыгымнарын һәм исәп-хисап чорына хезмәт хакын арттыру индексын тапкырлап билгеләнә.

4.2. Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр чыгымнары исәбенә эш бирүче тарафыннан федераль бюджетка, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бюджетына (производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәрен дә кертеп), Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды һәм территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына федераль законнар нигезендә хезмәт хакларына карата күчерелә торган түләүләр керә.

Хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр ($Нз_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Нз_i = Зот_i \times Снз \ ,$$

монда:

$Зот_i$ – исәп-хисап чорына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда i-муниципаль берәмлегә хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$Снз$ – хезмәт хакына карата күчерелә торган түләүләр ставкасы.

4.3. Исәп-хисап чорына башка чыгымнар ($Пр_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Пр_i = У_{усл} + У_{сос} + У_{смз} \ ,$$

монда:

$У_{усл}$ – хезмәт күрсәтүләргә чыгымнар;

$У_{сос}$ – төп чаралар бәясен арттыруга чыгымнар (капиталь төзелеш чыгымнарыннан тыш);

$У_{смз}$ – матди запаслар бәясен арттыруга чыгымнар һәм башка чыгымнар.

Исәп-хисап чорына әлеге чыгымнар ($У_{усл}$, $У_{сос}$, $У_{смз}$) исәп-хисап чорына кадәрге чордагы чыгымнарның һәр төрен ($У_{усл}$, $У_{сос}$, $У_{смз}$), чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше мөмкинлекләреннән чыгып, индекс-дефляторларга тапкырлап билгеләнә.

5. Инновацион белем бирү программаларын гамәлгә кертүче гомуми белем бирү учреждениеләренә акчалар бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_{in} = Ку_i \times N \ ,$$

монда:

$Ку_i$ – муниципаль берәмлектә Россия Федерациясе субъектларының гомуми белем бирү учреждениеләре конкурсында җиңгән учреждениеләрнең һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә инновацион белем бирү программаларын гамәлгә кертүче муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең саны;

$N$ – федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләренә бүлеп бирелә торган акчалар күләме.

Конкурста җиңүчеләр тарафыннан алынган акчалар гомуми белем бирү учреждениеләре өчен лаборатор җиһазлар сатып алу, аларны программа белән һәм методик яктан тәэмин итү, аларның матди-техник укыту базасын модернизацияләү

һәм педагогика хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм аларны яңадан әзерләү өлешендә инновацион белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә тотыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2010 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2010 елның 12 гыйнвары
№ 2-ТРЗ